Generated by Foxit PDF Creator © Foxit Software
http://www.foxitsoftware.com For evaluation only.

# ТАТАР ТЕЛЕ дәресе.

Укытучы: Ибраһимрова Альмира Хәмзә кызы .

Тема: САН.

Максат: 1) Г. Тукай турында сөйләшү, саннарның төрләре турында мәглүмат бирү.

2) Укучыларның сүз төркеме ( сан) турында белемнәрен үстерү һәм ныгыту.

3) Тарихыбызда булган кешеләр исемнәрен онытмау турында әйтү.

Җиһазлау: 1.Г.Тукай портреты. 2. Таблицалар: а) Саннар. б) Килешләр. в) Җөмләләр.

Generated by Foxit PDF Creator © Foxit Software
http://www.foxitsoftware.com For evaluation only.

# ДӘРЕС БАРЫШЫ.

## I. ОЕШТЫРУ МОМЕНТЫ.

1. Исәнләшү.

2. Дежур җавабы.

а) Бүген ..... апрель. Урамда көн .... . Сыйныфта ........ юк.
б) Дежур укучыга бирем: ЕГЕРМЕ АЛТЫНЧЫ АПРЕЛЬ- сүзтезмәсен килешләр белән төрләндерү.

## II. АКТУАЛЬЛӘШТЕРҮ.

1. Диктант.

1 Бирем: Сорау җөмләләрне искә төшерегез, һәм мисал китерегез.
2 Бирем: а)Сорау җөмләләргә җавап бирегез. (җавапларны язу)
-Г.Тукай -кем ул?
- Г.Тукай кайда һәм кайчан туган?
- „Туган тел” шигырен кем язган?
б) Г. Тукайның күп шигырьләрен үзе исән чагында мәктәп-мәдрәсәләдә көйләп җырлый торган булганнар.

2. „Туган тел” сүзтезмәсен тартым кушымчалары белән төрләндерегез.

## III. ДӘРЕСНЕҢ ТӨП ӨЛЕШЕ.

1. Сүз төркемнәрен искә төшерегез.
- Егерме алты нинди сүз төркеме?

2. Санның төркемчәләре белән танышу.( Таблица белән эшләү)

Микъдар саны: егерме алты.
Тәртип саны: егерме алтынчы.
Бүлем саны: егерме алтышар.
Чама саны: егерме алтылап.
Җыю саны: егерме алтышарлап.

Generated by Foxit PDF Creator © Foxit Software
http://www.foxitsoftware.com For evaluation only.

3.Җөмләләрне тәрҗемә итү.
Кушлавыч, Өчиле, Сасна, тагын Өчиле, Казан, тагын Өчиле һәм Кырлай. Кырлайдан соң Г. Тукай Җаекка элэгэ. Җаекта ул рус классында укый.

Бирем: исемнәрең килешен әйтеп чыгыгыз.

4. Бирем: текстны тәрҗемә итегез, һәм тексттан саннарны языгыз.

1911-1912 елларда Тукайның сәламәтлеге начарлана бара. Шулай да ул бу елларда Казан арты авылларында, Әстерхан, Уфа, Петербург шәһәрендә сәяхәт итә. 15(2) апрельдә бөек шагыйребезнең гомере өзелә. Шагыйребезнең шигырь һәм поэмалары, мәкалә, очерк һәм фельетоннары бүген дә әле безнең замандаш булып яши.

- Саннарның төркемчәсен әйтегез.

IV.ДӘРЕСНЕ ЙӨМГАКЛАУ.

1.Кабатлау.
- Дәрестә кем турында сүз барды?
- Кем ул?
-Үзегез белгәнегезне сөйләгез.
-ЕГЕРМЕ АЛТЫ нинди сүз төркеме?
-Санның төркемчәләрен искә төшерегез.

2.Өй эше: саннар белән җөмләләр төзеп язу.(5 җөмлә)

Generated by Foxit PDF Creator © Foxit Software
http://www.foxitsoftware.com For evaluation only.

Тема: ЖӨМЛӘНЕҢ БАШ ҺӘМ ИЯРЧЕН КИСӘКЛӘРЕ.

Максатлар: 1. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре турында төшенчә бирү.

2. Темага бәйле сүзләр белән танышуны дәвам итү.

3. Татар телен рус теле белән чагыштыру формасында өйрәнүгә кызыксыну уятырга тырышу.

Әдәбият:

1.Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С., Сазонова Н.Г. Татар теленнән контроль эшләр һәм тестлар. Казан.-Тарих, 2003.

2.Ягъфәрова Р.Х., Фәтхуллова К.С. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 5 нче с-фы өчен д-лек.- Казан: татар. кит. нәшр.

3.Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 5 нче с-фы өчен д-лек/ Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. (татар балалары өчен) .Казан: Мәгариф, 2004. 121-122 б.б.

Generated by Foxit PDF Creator © Foxit Software
http://www.foxitsoftware.com For evaluation only.

# ДӘРЕС БАРЫШЫ.

I. ОЕШТЫРУ МОМЕНТЫ.

1.Исәнләшү.

2.Дежур җавабы.

Бирем: Ия белән хәбәр сүзләрен килешләр белән төрләндерегез. Килеш кушымчаларын күрсәтегез.

II.АКТУАЛЬЛӘШТЕРҮ.

1. Диктант.

Җөмләнең баш кисәкләре – ия, хәбәр. Җөмләнең иярчен кисәкләре - тәмамлык, аергыч, хәл.
Ия: Кем? Нәрсә?
Хәбәр: Нишли? Нишләде? Нишләр?
Тәмамлык: Кемне? Нәрсәне? Кем белән? Нәрсә белән? Нәрсәгә?
Хәл: Кая? Кайдан? Кайчан? Ни өчен?
Аергыч: Нинди? Кайсы? Кемнең? Нәрсәнең? Ничәнче?

2.а) Җөмләнең баш кисәкләрен кабатлау.

б) Җөмләнең иярчен кисәкләрен кабатлау.

III.1.Карточка буенча эш.(вариатнлап)
I вариант: 19 б. II вариант: 20 б.
Бирем: Сүзләрдән җөмләләр төзеп языгыз.

2. Бирем: а) җөмләләрне күчереп языгыз.
Ямьле яз килеп җитте. Җылы яктан кошлар кайтты. Урамнарда гөрләвекләр ага.Һавада тургай сайрый. Җылы көннәр озыная.

б) Бирем: Язылган җөмләләрнең баш һәм иярчен кисәкләрен күрсәтегез.

в) Бирем: Бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз.

Сүзләр: Борынгы, тарихи, төрле.

г) Бирем: Баш һәм иярчен кисәкләрен күрсәтегез.

Generated by Foxit PDF Creator © Foxit Software
http://www.foxitsoftware.com   For evaluation only.

IV.ЙОМГАКЛАУ.

1.Җөмләләрнең баш кисәкләре турында кабатлау.

2.Җөмләләрнең иярчен кисәкләре турында кабатлау.

3.Билгеләр кую.

4.Өй эше: 5 җөмлә язып, баш һәм иярчен кисәкләрен күрсәтергә.